РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

423303, Азнакаевский район, с. Агерзе, ул.Г.Ахметовой, д.14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башкарма
комитеты

423303, Азнакай районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 16» август 2019 ел № 9

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районының
«Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге торак пунктларында гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы Федераль закон,«Җирле референдум турында» 24.03.2004 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә
Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзарасалым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Н.Н.Хәсәнов

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге
Башкарма кмитет карарына кушымта №1
16 август 2019 № 9

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 31 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түли.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 2 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,

в) күпбалалы гаиләләр,

түләү күләме җирле референдум (гражданнар җыенында) карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәрнамә) бланкы, җирлек сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән, гражданнарга җиткерелә: http://aznakayevo.tatarstan.ru шулай ук почта элемтәсе аша имза яисә юллама тапшыру юлы белән (әлеге Тәртипкә кушымта).

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнардан кергән үзарасалым акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) башкаруга, Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бирелә. https://uslugi.tatarstan.ru/

8. Түләү фактын раслап, керемле касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзарасалым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан РеспубликасыАзнакай
муниципаль районы "Әгерҗе авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге торак пункнктларында
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ________

Түләүченең Ф.И.О. ______________________
____________________________________________
Адрес: ____________________________________
_______________________________ нигезендә
Сезгә ________ кадәр үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
__________ сум
реквизитлар: ______________________________
алучыбанкыБИК ____________________________
Сч. № ____________________________________
Сч. № ____________________________________
ИНН ______________________________
КПП ______________________________________
КБК ______________ ОКАТО ______________
Түләүнеңбилгеләмәсе ___________________________
____________________

Җитәкче ____________ ________________
М.П. (имза) (расшифровка)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Уведомление)№ ____________
бюджеткаүзарасалымбуенчабертапкыртүләүтүләүтурында________________
*(муниципальберәмлекисеме)*
__________ сум
Түләүченең Ф.И.О. ______________________________
Адресы: __________________________________
____________________________________________
«__» _______________ 20__ г. ______________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)_____ авылҗирлегеБашкармакомитетындатутырыла һәм кала.*